**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КҮЗКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«15» ноябрь 2022 ел Күзкәй авылы № 20

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2022 елның 14 октябрендәге 16 санлы карары белән расланган «2022-2024 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлегендә юл хәрәкәте иминлеге» программасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2018-2024 елларда юл хәрәкәте иминлеген көчәйтү» федераль максатчан программасы концепциясен раслау турында» 2018 елның 08 февралендәге 1-р санлы боерыгын тормышка ашыру максатында

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2022 елның 14 октябрендәге 16 санлы карары белән расланган «**2022-2024 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлегендә юл хәрәкәте иминлеге**» программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Программаны финанслау» 3 бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

« Программаны финанслауның гомуми күләме **300,00** мең сум тәшкил итә.

Муниципаль бюджетлардан финансларны бүлүче – авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе, район Башкарма комитеты Җитәкчесе. Финанслауның күрсәтелгән күләме тиешле финанс елына бюджет формалаштырганда төгәлләштерелергә тиеш. Моннан тыш, мөмкин булганда, район бюджеты акчалары, максатчан һәм ирекле иганәләр җәлеп ителәчәк».

1.2. **2022-2024 елларга Күзкәй авыл җирлеге буенча юл хәрәкәте иминлеген көчәйтү программасын** яңа редакциядә бәян итәргә:

2022-2024 елларга Күзкәй авыл җирлеге буенча юл хәрәкәте иминлеген көчәйтү программасы

| № п/п | Объект исеме | Ераклык | Финанслау чыганаклары | | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Җирле бюджет, сумнарда | | | |
| | | | 2022 | 2023 | 2024 | |
| 1 | Авыл эчендәге юлларны төзү, ремонтлау һәм реконструкцияләү: | км | - | - | - | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 | Җирлек торак пунктларында тукталыш павильоннарын урнаштыру | - | - | - | - | |
| 3 | Җирлектә гомуми белем бирү учреждениеләре каршында балалар автомобиль мәйданчыклары | - | - | - | - | |
| 4 | «Ясалма тигезсезлек» урнаштыру: | берәмлек | - | - | - | |
| 5 | Юлның машиналар йөрү өлешенә разметка | 4 берәмлек | 76,824 | 76,824 | 100,0 | |
| 5.1 | Күзкәй авылы җәяүлеләр кичүе | 3 берәмлек | 57,618 | 57,618 | 60,0 | Җирле бюджет |
| 5.2 | Яңа Байлар авылы җәяүлеләр кичүе | 1 берәмлек | 19,206 | 19,206 | 40,0 | Җирле бюджет |
| 6 | Авыл җирлегендә юл билгеләре урнаштыру: | 2 берәмлек | 23,176 | 23,176 | - | |
| 6.1 | Яңа Байлар авылы, Октябрь ур. | 2 | 23,176 | 23,176 | - | Җирле бюджет |
| 7 | Юл буе сервисы объектлары булган участокларда юлларны яктырту | - | - | - | - | |
| 8 | Металлдан барьер коймалар урнаштыру | - | - | - | - | |
| | БАРЛЫГЫ | | 100,0 | 100,0 | 100,0 | |

2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Күзкәй авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Яковлева Л. С. йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Э.Р. Гәрәев

Исполнительный комитет Кузкеевского сельского поселения ИНН 1639032350